ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АКТАНЫШСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

пр. Ленина, дом 17, с. Актаныш, 423740

Ленин пр.,17 йорт,Актаныш ав.,423740

Тел.(85552)3-44-22,факс (85552) 3-44-14, E-mail:aktanysh@tatar.ru, www.aktanysh.tatarstan.ru

ПОСТАНОВЛЕНИЕ
____________

КАРАР
№ _____

**Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы «Пучы урта гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесенең структур бүлекчәсе «Зөбәер башлангыч гомуми белем бирү мәктәбе-балалар бакчасы» белем бирү учреждениесен үзгәртеп оештыру турында**

Россия Федерациясе Граждан кодексының 61-64 статьялары, «Россия Федерациясендә бала хокукларының төп гарантияләре турында» 124-ФЗ номерлы Федераль законның 13 статьясы, «Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законның 9 статьясындагы 1 өлешенең 4 пунктына таянып, 2022 елның 26 маеннан Актаныш муниципаль районы муниципаль белем бирү оешмасын үзгәртеп оештыру яки бетерү турында карар кабул итү нәтиҗәләрен бәяләү комиссиясенең 27 нче номерлы бәяләмәсе, 2022 елның 27 апреленнән Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Зөбәер авылы гражданнар җыенының 3 номерлы беркетмәсе нигезендә

**КАРАР БИРӘМ:**

1. «Пучы урта гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесенең структур бүлекчәсе «Зөбәер башлангыч гомуми белем бирү мәктәбе-балалар бакчасы» белем бирү учреждениесен 2022 елның 27 маеннан «Пучы урта гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесенең филиалы, «Зөбәер балалар бакчасы» белем бирү учреждениесенә үзгәртеп оештырырга.

2. «Пучы урта гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе директоры А.Р. Шәйхетдиновага:

- Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районының «Пучы урта гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе Уставына үзгәреш проекты әзерләргә;

- хезмәт законнары нигезендә үзгәртеп оештырыла торган белем бирү учреждениесе штатларын кыскарту процедурасын үткәрүне тәэмин итәргә;

- Актаныш муниципаль районы «Пучы урта гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесенең структур бүлекчәсе «Зөбәер башлангыч гомуми белем бирү мәктәбе-балалар бакчасы» мәгариф учреждениесен закон нигезендә билгеләнгән тәртиптә үзгәртеп оештырырга.

3. Әлеге карарны Актаныш муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматының рәсми порталында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Актаныш муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасары Л.Ф.Нурлыевага йөкләргә.

Җитәкче Р.А.Ильясов